*СОГЛАСОВАНО*
*Председатель первичной профсоюзной организации МБДОУ «Детский сад №121 «Сабантуй»*
_________ А.Г. Исмаилова
*«28» августа 2025 г.*
*Введено в действие приказом заведующего*
*«28» августа 2025 г. №260*

*УТВЕРЖДАЮ*
*Заведующий МБДОУ «Детский сад №121 «Сабантуй»*
_________ Г.Р. Ахметзянова
*«28» августа 2025г.*
*Рассмотрено и утверждено на педагогическом совете коллектива МБДОУ №121*
*«28» августа 2025 г.*
*Протокол № 1*

# ПРОГРАММА ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ

социально – педагогического направления

# «УЙНЫЙ, УЙНЫЙ ӨЙРӘН ӘБЕЗ »

**для детей дошкольного возраста от 5 до 7 лет**

Составитель:
Салахова Л.Р.

г. Набережные Челны, 2025 г.

**Аңлатма язуы.**

Телне яхшы белүдә төп метод – сөйләшү. Балада сөйләшә белергә өйрәнү процессы белән бергә абстракт фикерләү нигезе дә салына. Мәсәлән, туп, курчак, шар... Болар конкрет әйберләр, уенчыклар. Ә менә яхшы, начар, матур, ямьсез – нәрсә ул? Алар конкрет әйбердән ни өчен аерылалар?

Татар телен өйрәнү тулаем тел белеменә, психологиягә, педагогикага һәм туган телне яратуга нигезләнә.

Туган телне өйрәнгәндә, укучыларның фикер йөртү сәләте үсә.

Балалар бакчасында татар телен өйрәнгәндә балаларга үз туган теленең матурлыгын аңларга, аны яратырга, халкыбызның иҗади байлыгы һәм чын тарихыибелән кече яшьтән үк тирән кызыксыну уятырга ярдәм итә.

Һәр телнең асыл хәзинәсе сүзлекләрдә туплана.

Татар теленә өйрәнү баланың үз тырышлыгы, үз кызыксынуы белән генә була.

Тәрбияче һәр баланың темпераментын, нәрсә белән мавыгуын, нәрсәгә һәвәслеген, зиһенен, хәтерен, дикъкатен, ихтияр көчен, гомуми үсешен, фикерләү сәләтен, танып белү эшчәнлеге үзенчәлекләрен, эш-хәрәкәт темпын исәпкә алып эш итәргә тиеш, коллектив эченә алып керергә, күмәк эштә актив катнашуына ирешергә кирәк. Моңа ирешү өчен балалар яраткан уен эшчәнлегеннән киң файдаланыла. Һәр дәрес мавыктыргыч, дидактик, хәрәкәтле, такмаклы уеннар белән үрелеп барырга тиеш.

Түгәрәк эше күрсәтмәлелеккә бай: анда сюжетлы картиналар да, төрле җисем рәсемнәре дә, логик күнегү, уен материалы, башваткыч, табышмак, тел шомарткычлар да бар.

Туган тел үз телендә сөйләшүче халыкның күп гасырлар буе тупланган рухи хәзинәсен чагылдыручы, тылсымлы сихри көзгесе дә. Аның укучыларны әдәпле, әхлаклы, мәгърифәтле һәм мәдәниятле итеп тәрбияләү мөмкинлекләре чиксез.

Баланың аңы үсү: белеме арту, аның чынбарлыкны танып белү тирәлеге киңәю һәм чын кеше булып тәрбияләнүе үз туган телен яхшы белүгә бәйле. Туган халкыңны яратканда, аңа олы ихтирам тәрбияләгәндә, аның барлык мирасын сакларга һәм үстерергә-баетырга омтылганда гына, телне яхшы белүгә ирешергә мөмкин. Шуңа күрә, бададарныж логик фикерләү, образлы уйлау сәләтләре үссен өчен,тщрбияче аларның туган телне яхшы белүләренә һәм кече яшьтән үк зәвык белән нәфис итеп сөйләргә һәм язарга өйрәнүләренә омтылырга тиеш.

Бүгенге көндәтатар теле тәрбиячененең төп бурычы – балаларны белемле, рухи яктан бай, әхлаклы, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Бу бурычлар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Шулар арасында иң әһәмиятлесе,үтемлесе һәм нәтиҗәлесе – уеннар.

Сөйләм осталыгын үстерүдә һәм дөрес итеп сөйләргә өйрәтүдә коммуникатив уеннар гаять зур әһәмияткә ия, чөнки алар һәрвакыт сүзләр белән бәйләп алып барыла. Уен барышында балалар сүзләрне күмәк кабатлыйлар, яңа сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнәләр, бер – берсе белән аралашалар. Коммуникатив уен шулай ук уйланылган( шартлы), проблемалы ситуаци- ялэр барлыкка китерү һәм аларны уйнау (чишү) төрендәге күнегүләр дә. Ситуация сөйләмгә этәргеч була. Мондый уеннарда балаларда фикерләүне эшкә җигү нәтиҗәсендә нәрсәдер әйтү ихтыяҗы барлыкка килә. Образлы фикерләү логик фикерләү белән бергә алып барыла. Эш – хәрәкәтләр барышында

әйтелгән сүзләр хәтердә ныграк сеңеп кала. Хәрәкәтләр белән башкарылган сөйләм әйтелгән, уйланылган образны(сурәтне) җанлырак итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Коммуникатив уеннар телдән сөйләмне үстерү, камилләштерү өчен баланы җанлы сөйләмгә (диалог) яки күмәк сөйләмгә (полилог) тарту максатыннан үткәрелә. Уен вакытында бала эзләнә, үз фикерен курыкмыйча әйтә ала. Катнашучылар бер-берсенә ярдәм итә, белгәннәре белән уртаклаша. Бу исә балаларда игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатлары һәм үз уңышларына шатлану хисе тәрбияли. Оялчан балалар онытылып, үзләре дә сизмәстән, уенга кушылалар. Шулай итеп, коммуникатив уеннар балаларга аралашу өчен тормышчан шартлар тудыра, чын тормышка күпер сала.

**Программаның максаты**

Татар теленә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү; татар теленнән алган белемнәрен системага салу,ныгыту; татар теле белән ни дәрәҗәдә кызыксынуларын белү; балаларның мөстәкыйль фикер йөртергә , үзара дуслык хисе тәрбияләргә, тапкырлыкка, җитезлеккә өйрәтү.

Балага белем һәм тәрбия уен аркылы аеруча кече яшьтә әйбәт бирелә.Уйнаган чакта бала күп нәрсәне таный, күнекмәләр ала. Шуны истә тотып мин, балалар белән татар телен ныгырак үзләштерү максатыннан, “Уйный – уйный өйрәнәбез” түгәрәге алып барырга дигән фикергә килдем. Уен баланың шул фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген , ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, тапкырлыгын үстерә, аны милли бердәмлек рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә.Яңа программалар балаларның ныклы белем, тотрыклы күнекмәләр алуын гына түгел, мөстәкыйль рәвештә танып-белү эшчәнлеге белән кызыксынуларын да уятуны һәм шуны кече яшьтән үк кешенең күнекмәсенә әйләндерә баруын күздә тота.

**Программаның бурычлары**

1.балаларның психологик үзенчәлекләрен истә тотып, уен эшчәнлеген оештыру;
2.уенны баланың һәр төр эшчәнлегенә кертү;
3.һәр баланың характерын, темпераментын, шәхси мөмкинлеген, теләген истә тоту;
4.предметлы уен тирәлеге булдыру.

**Программаның актуальлеге**

Баланы төрле яклап үстерү өчен, иң беренче чиратта, аның нәрсәгә сәләтле булуын ачыклау да җитә. Бу очракта күпләгән санда түгәрәкләргә йөртүдән тыш, аңа туры килә торган берсен сайлап алырга мөмкин. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен – үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә – юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә

**Программаның билгеләнеше**

4-6 яшьлек балалар белән “ Уйный – уйный өйрәнәбез” түгәрәге айга 4 тапкыр, атнага 1 мәртәбә көннең икенче яртысында уза. Шөгыльнең озынлыгы– 30 минут.

**Түбәндәге принципларга таянып эшләү мәҗбүри:**

- педагогның әзерлеге;

- бай эчтәлекле, темаларның һәм методик алымнарның төрлелеге;
- педагогик процессны оештыруның бөтен формаларын куллану;
- барлык баланың максималь актив катнашуы;
- иптәшләре һәм педагоглар белән хезмәттәшлек.

## Программа эчтәлеге.
## Уеннар исемлеге.
## *1.”Тылсымлы сөлгеләр”*

***Уенга күрсәтмә:*** *җыелмада төрле бизәкләр ясалган 40 карта бар. Уен башланыр алдыннан, детальләрне агач нигезндә алырга кирәк. Уенчы бизәкне беренче номерлы карточка буенча җыя башлый һәм тәртип буенча дәвам итә. Бизәк җыю өчен вакыт чикләнмәгән.*

***Уен максаты:****үрнәк буеча бизәк җыю.*

***Тәкьдимнәр:***

*1.Бзәкне агач нигез өстендә җыярга киңәш ителә.*

*2.Уен башланыр алдыннан, фигураларны игътибар белән карарга һәм өйрәнергә кирәк.Карточкалар детальләр 2D сүрәтендә бирелгән.*

## *2.”Түбәтәй”*

***Уенга күрсәтмә:****уен башланыр алдыннан төркемнәр үзара ярышачакмы, әллә катнашучылар берәрләп уйнаячакмы икәнен хәл итергә кирәк.*

***Уен максаты:****уен таячыклары ярдәмендә түбәтәйне сәйләннәр белән бизәү***.**

***Тәкьдимнәр:***

*1.Өстәлгә агач түбәтәй, 2 уен таякчыгы, сәйләннәр салынган кәрҗин һәм ком сәгате куела.*

*2.Уен җәшланганда сәйләнле кәрҗинне түбәтәйдән 20 см ераклыкта урнаштырырга кирәк.*

*3.Түбәтәйне бизәү өчен, бер уенчыга 30 секунд вакыт бирелә.Уен йөреше санын уенчылар үзләре хәл итә ала.*

*4.Һәр уңышлы йөреш өчен,уенчыга фишка бирелә.Иң күп фишка җыйган уенчы җиңүче була.*

## *3.”Манара”.*

***Уенга күрсәтмә:****комплекттагы брошюраның һәр битендә бер модель ясалган. Аны төзү өчен аста кирәкле элементларның төре һәм саны бирелгән.Модельләр катлаулылык дәрәҗәсе буенча урнаштырылган.Сары төс белән җиңелрәк, кызыл төс белән катлаулырак модельләр күрсәтелгән.*

***Уен максаты:*** *тотрыклы рәвештә һәм бернинди терәүсез торучы 3D моделен өскәтаба төзү.*

***Тәкьдимнәр:***

*1. Корылманы горизанталь һәм яссы өслектә төзергә кирәк.*

*2. Өслекнең кытыршы булуы яхшырак.*

***3.** Уен башланыр алдыннан фигураларны игътибар белән карап өйрәнергә кирәк. Брошюрада төзү элементлары 2D сүрәтендә бирелгән.Шул сәбәпле, кырылманы бу элементларның 2D һәм 3D конструкцияләрендәге урыны бер төрле булмавын исәпкә алып тезү мөһим. Шуңа күрә  һәр фигураның яссы проекциясен аңларга, аларны һәрьяклап игътибар белән карарга кирәк.*

## *4.”Читекләр”*

***Уенга күрсәтмә:**уен башланыр алдыннан, тукымадан ясалган уен кырын җәеп куярга кирәк. Аның өстенә,рәсемле якларын өске каратып, барлык читекләр һәм уен шакмаклры куела.*

***Уен максаты:**мөмкин кадәр күбрәк балл җыю. Бер төстәге читекләр- 1 балл, Ике төстәге читекләр – 2 балл. Өч төстәге читекләр – 3 балл.*

***Тәкъдимнәр**:*

*1.Читекне алу өчен,тиешле төстәге читекне башка уенчылардан тизрәк табарга кирәк.Читекнең төсе яки төсләр комбинациясе унчылар чиратлап ташлый торган уен шакмаклары ярдәмендә билгеләнә.*

*2.Бер шакмакны ташлаганда, аның өске ягындагы төстәге читекне табарга кирәк. Бу читек бер төстә булырга тиеш.*

*3. Ике шакмак ташлаганда, шакмаклардагы төсләрдә булган читекне табарга кирәк.Бу читек шушы ике  төстә булырга тиеш.*

*4.Өч шакмакны ташлаганда, читек аларның өске якларындагы өч төстә булырга тиеш.*

### *5. “Җәйге алан”*

***Уенга күрсәтмә:**уен башланыр алдыннан тукымадан ясалган уен кырын җәяргә кирәк. Аның өстенә кире яклары белән уен фишкалары куела. Уеда катнашучылар берәр кәрҗин ала.*

***Уен максаты:**кәрҗингә  4 “җиләк” яки 4 “гөмбә”җыю.*

***Тәкъдимнәр**:*

*1. Катнашучылар чиратлап йөри. Һәр уенчы үз йөреше вакытында бер фишкага чүкеч белән суга. Бу сугу фишканы рәсемле ягы белән өскә әйләндерегә тиеш. Бер йөреш вакытында 2 тапкыр сугарга ярый. Әгәр беренче әйләнгән фишкада “гөмбә”рәсеме чыга икән, катнашучы “гөмбәләр” генә җыя. “Җиләк” рәсеме чыкса,”җиләк”кенә җыя.*

*2.Уен барышында “бүре”фишкасы чыга икән, катнашучы барлык җыелган фишкаларын кырга ташлый да уенны яңадан башлый.*

*3. Кәрҗинен бернче булып тутырган уенчы җиңүче була.*

## *6.”Кара- кара”*

***Уенга күрсәтмә:**башта уен кыры әзерләнә.Ул төсле кырлы карталардан квадрат формасында җыела. Ак кырлы һәм “Кара- кара “ дип язылган карта үзәктә урнаштырыла. Аның өстенә,язулы яклары белән аска*

*каратып, биремле карталар куела. Бу карточкаларның икенче якларына К, А, Р хәрефләре язылган.*

***Уен максаты:****карточкалар ярдәмендә Кара-кара сүзләрен язарга.*

***Тәкьдимнәр****:*

*1.Карточкада бер объект сүрәтләнгән икән, аны уен кырында табып күрсәтергә кирәк.*

*2. Карточкада төсле түгәрәкләр сүрәтләнгән булса, шундый ук түгәрәеләр ясалган карточканы табарга кирәк. Бу карточкада түгәрәкнең бер берсенә карата урнашу димәк шундый булырга тиеш.*

*3.Карточкада төсле кырлы ике рамка һәм сорау билгесе сүрәтләнгән булса, ике бертөрле монстрны табарга һәм тиешле кырларда күрсәтергә кирәк.*

*4.Карточкада төсле кырлы ике рамка һәм “+” билгесе сүрәтләнгән булса туры килгән кырлардагы саннарны табарга, аларны кушарга һәм җавапны әйтергә кирәк.*

*5. Карточкада төсле кырлы ике рамка һәм “-” билгесе сүрәтләнгән булса туры килгән кырлардагы саннарны табарга, зуррак саннан кечрәген алырга һәм җавапны әйтергә кирәк.*

## *7.”Мин булдырам”*

***Уенга күрсәтмә:****уен комплектына төрле төстәге 30 детальдән торган агач нигез, төрле катлаулыктагы 80 карточка – схема кирә.*

***Уен максаты:*** *схемалар буенча модельләр ясау.*

***Тәкьдимнәр****:*

*1.Сары һәм кызгылт- сары төсле карточкалар беренче һәм икенче дәрәҗәдәге катлаулыкка ия. Мондый конструкцияләр яссылыкта горизанталжҗ юнәлештә җыела.*

*2.Ачык тяшел һәм яшел төстәге карточкалар өченче һәм дүртенче дәрәҗәдәге катлаулыкка ия.Мондыйй конструкөияләр яссылыкта вертикаль юнәлештә җыела.*

*3.Зәңгәрсу карточкалар дәрәҗәдәге катлаулыкка ия. Бу карточкалар буенча канструкцияләр ясылыкта 3D модель рәвешендә җыела.*

*4.Шәмәхә төстәге карточкалар дәрәҗәдәге катлаулыкка ия. Мондый конструкцияләр яссылыкта горизанталь юнәлештә җыела.*

## *8.”Нәрсә бу?”*

***Уенга күрсәтмә:****башта уен өчен кирәк булган көзгеле тоткычны җыеп әзерләргә кирәк. Моның өчен еиртәләрне бер – берсенә кертеп*

*куярга,аннары көзгеле токтычка тоташтырырга кирәк.Уен өчен рәсемле карточкалар әзерләп куела.*

***Уен максаты:****карточкада нәрсә сүрәтләнгәнен башка уенчылардан алданрак белү.*

***Тәкьдимнәр****:*

*1.Бер йөреш вакытында һәр уенчы бер тапкыр җавап бирә.Әгәр бер йөреш вакытында рәсемне беркем дә танымый, алып баручы уөзгеле токтычны уңга таба 90 градуска бора.Хәзер һәр уенчы рәмемнең яңа элементын күрә.Уенчылар чиратлап үз җаваплары әйтәләр.Әгәр дөрес җавап булмаса,алып баручы көзгеле токтычны тагын уңга таба 90 градуска бора. Алып баручы аны барлыгы 3 тапкыр бора ала. Әгәр шуннан соң да уенчылар җавапны әйтә алмаса, карточка алыштырыла.*

### ***9.Башваткыч.***

***Уен максаты:*** *фигураларны җыю ярдәмендә танграмнардан 2D объектларын ясау.*

***Уенга күрсәтмә:*** *комплекта 4 төр танграм һәм брошюра бар.Брошюраның һәр битендә төрле танграм деталҗләрен төгәл кабатлап җыярга тиешле 2D объект сүрәтләнгән.*

***Тәкьдимнәр****:*

*1.Т- формасындагы танграм. 4 элементтан тора.*

*2.Квадрат формасындагы танграм. 7 элементтан тора.*

*3.“Йөрәк”формасындагы танграм.9 элементтан тора.*

*4. “Йомырка” формасындагы танграм.9 элементтан тора.*

*Брошюра 4 өлешкә бүленгән.Һәр өлештәге биремнәр билгеле бер танграм беән эшләү өчен каралган.Фигура ясау вакыты чикләнмәгән.*

### ***10.Мин төзүче.***

***Уен максаты:***яссы агач кисәкләреннән *3D модельләрен төзү.*

***Уенга күрсәтмә:*** *комплектта 200 бертөрле яссы кисәге, модельләр төзү өчен үрнәкләр тупланган брошюра бирелгән. Бөтен модельләр өстәмә тоташтыргыч җайланмаларсыз һәм материалларсыз төзелә.*

## **Шөгыль структурасы:**

Оештыру этабы

- эмоциональ кәеф булдыру;

1. Мотивацияләү этабы

- шөгыль темасы / уен исеме;

- әлеге тема/уен буенча балаларның башлангыч белем дәрәҗәсен ачыклау;

II. Гамәли этап

- булган билгеләмәләр нигезендә яңа мәгълүмат бирү (уен/кагыйдәләр белән танышу);
- танып белү процессларын (үзләштерү, хәтер, фикерләү, күзаллау) һәм иҗади сәләтләрне үстерүгә юнәлтелгән биремнәрне башкару;
- уен күнекмәләрен өйрәнү;

III. Йомгаклау этабы (рефлексия)

- педагог/балаларның нәтиҗәләрне язуы;
- алынган белемнәрне гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау;

# Көтелгән нәтиҗә

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белүе,

Татар телендә сөйләшү теләге ;

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белүе;

Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.

Сөйләм теле бәйләнешле һәм эзлекле булу, сөйләмнең мәгънә ягын аңлау, җөмләнең синтаксик төзелеше, сөйләм теленең аваз ягын камилләштерү.

Баланың күмәк сөйләмдә актив катнаша белүе.

Гаилә белән балалар бакчасы арасында җылы мөнәсәббәт урнашу.

## *“Уйный-иуйный өйрәнәбез” түгәрәген тематик планнаштыру*

**Уртанчылар төркеме өчен (4-5 яшь) перспектив еллык план**

| ай | атна | уен | тема | бирем |
|---|---|---|---|---|
| | I | җәйге алан | уен белән танышу | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | II | читекләр | уен белән танышу | читекләрне табу |
| | | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | III | түбәтәй | уен белән танышу | сәйләннәрне урнаштыру |
| | | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | IV | мин булдырам | уен белән танышу | схема кулланмыйча объектлар ясау (малай, кыз,йорт) |
| | | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-5 карточкалар |
| октябрь | I | нәрсә бу? | уен белән танышу | рәсемнәрнең исемнәрен әйтергә өйрәнү |
| | | нәрсә бу? | төркем уены | рәсемнәрнең исемнәрен әйтергә өйрәнү |
| | II | тылсымлы сөлгеләр | уен белән танышу | 1-3 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-3 карточкалар |
| | III | мин төзүче | уен белән танышу | схема кулланмыйча төзү |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Чәчәк” схемасы (өстәмә) |
| | IV | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| ноябрь | I | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | II | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | III | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-5 карточкалар |
| | | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-5 карточкалар |
| | IV | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| декабрь | I | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | II | мин төзүче | схема буенча төзү | “Үрмәкуч” схемасы 9нчы бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Стеллаж” схемасы 4нче бит |
| | III | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | IV | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| гыйнвар | II | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | III | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-7 карточкалар |
| | | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-7 карточкалар |
| | IV | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| февраль | I | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | II | мин төзүче | схема буенча төзү | “Үрмәкуч2” схемасы 10нчыбит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Өстәл белән эскәмияләр” схемасы (өстәмә) |
| | III | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | IV | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| март | I | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | | түбәтәй | төркем уены | сәйләннәрне урнаштыру |
| | II | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-7 карточкалар |
| | | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-7 карточкалар |
| | III | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| апрель | I | мин төзүче | схема буенча төзү | “Ажур шакмак” схемасы15нче бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Өстәл” схемасы 17нче бит |
| | II | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | III | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | | читекләр | төркем уены | читекләрне табу |
| | IV | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| май | I | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-15 карточкалар |
| | | мин булдырам! | объектлар ясау | 1-15 карточкалар |
| | II | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем уены | кем күбрәк җавап таба |
| | III | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 1-10 карточкалар |
| | IV | мин төзүче | схема буенча төзү | “Түбә” схемасы 1нче бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Баскыч” схемасы 3нче бит |

## Зурлар төркеме өчен (5-6 яшь) перспектив еллык план

| ай | атна | уен | тема | бирем |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | башваткыч | уен белән танышу | Т формасындагы танграм |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | Т формасындагы танграм |
| | II | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | III | мин булдырам | объектлар төзү | кызыл сары карточкалар |
| | | мин булдырам | объектлар төзү | кызыл сары карточкалар |
| | IV | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| октябрь | I | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 15-30 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | 15-30 карточкалар |
| | II | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | III | мин төзүче | схема буенча төзү | "Түбә" схемасы 1нче бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | "Баскыч"схемасы 3нче бит |
| | IV | кара кара | уен белән танышу | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| ноябрь | I | манара | схема буенча манара җыю | сары дәрәҗә |
| | | манара | схема буенча манара җыю | сары дәрәҗә |
| | II | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | IV | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| декабрь | I | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | II | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | IV | мин төзүче | схема буенча төзү | "2 катлы стеллаж" 4нче бит схемасы нигезендә |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | "Пирамида" схемасы 12нче бит |
| | II | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| гыйнвар | III | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | IV | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| февраль | I | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | II | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | | түбәтәй | төркем уены | эстафета |
| | IV | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| март | I | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | II | мин төзүче | схема буенча төзү | ”Трамплин” схемасы 19нчы бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Өчпочмаклы манара” схемасы 6нчы бит |
| | III | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| апрель | I | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | II | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | | җәйге алан | төркем уены | җиләк, гөмбә җыю |
| | III | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | IV | түбәтәй | төркем уены | парлар ярышы |
| | | түбәтәй | төркем уены | эстафета |
| май | I | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | тылсымлы сөлгеләр | бизәкне ясау | бала дәрәҗәсенә карап |
| | II | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | III | мин төзүче | схема буенча төзү | “Өстәл белән урындыклар” схемасы 17нче бит |
| | | мин төзүче | схема буенча төзү | “Дүртпочмаклы манара” схемасы 8нче бит |
| | IV | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |

## Мәктәпкәчә яшьтәге төркем өчен (6-7 яшь) перспектив еллык план

| ай | атна | уен | тема | бирем |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | мин булдырам | объектлар төзү | кук төсле карточкалар |
| | | мин булдырам | объектлар төзү | кук төсле карточкалар |
| | II | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | III | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | “Шакмак” танграмы |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | “Шакмак” танграмы |
| | IV | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | манара | схема буенча манара җыю | кызыл сары дәрәҗә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| октябрь | I | манара | схема буенча манара җыю | кызыл сары дәрәҗә |
| | II | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | III | мин төзүче | парлап объект төзү | “Өстәл б/н урындыклар схемасы 17нче бит |
| | | мин төзүче | парлап объект төзү | “Күпер” схемасы 23нче бит |
| | IV | түбәтәй | төркем ярышы | эстафета |
| | | балалар сайлавы буенча | | |
| ноябрь | I | мин булдырам! | объектлар төзү | күк төсле карточкалар |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | күк төсле карточкалар |
| | II | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | III | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | “Шакмак” танграмы |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | “Шакмак” танграмы |
| | IV | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | манара | схема буенча манара җыю | кызыл сары дәрәҗә |
| декабрь | I | манара | схема буенча манара җыю | кызыл сары дәрәҗә |
| | II | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | III | мин төзүче | парлап объект төзү | “Тәрәзә” схемасы 20нче бит |
| | | мин төзүче | парлап объект төзү | “Тәрәзәле йорт” схемасы 32нче бит |
| | IV | түбәтәй | төркем ярышы | “минем кул-синең кул” форматында ярышма |
| | | балалар сайлавы буенча | | |
| | II | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| гыйнвар | IV | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| февраль | I | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | II | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | IV | мин төзүче | парлап объект төзү | “Кораб” схемасы 30нчы бит |
| | | мин төзүче | парлап объект төзү | “Самолет” схемасы 25нче бит |
| март | I | түбәтәй | төркем ярышы | эстафета |
| | | балалар сайлавы буенча | | |
| | II | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| апрель | I | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | | тылсымлы сөлгеләр | парлап бизәкне ясау | 20-40 карточкалар |
| | II | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | манара | схема буенча манара җыю | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | | нәрсә бу? | төркем ярышы | кем күбрәк җавап таба |
| | IV | мин төзүче | парлап объект төзү | “Цирк” схемасы 36нчы бит |
| | | мин төзүче | парлап объект төзү | “Асылмалы күпер” схемасы 34нче бит |
| май | I | түбәтәй | төркем ярышы | “минем кул-синең кул” форматында ярыш |
| | | балалар сайлавы буенча | | |
| | II | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | мин булдырам! | объектлар төзү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | III | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | | кара кара | төркем ярышы | биремнәрне үтәү |
| | IV | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |
| | | башваткыч | дәфтәр белән эшләү | бала дәрәҗәсенә карап |

## Кулланылган әдәбият (укытучы өчен).

1. Амонашвили Ш.А. Уйныйбыз да, укыйбыз да. Казан.Татарстан китап нәшрияты,1990.
2. Бала бишеге – гомер ишеге. Яр Чаллы. Идел – йорт нәшрияты, 2002.
3. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан. “ Дом печати” нәшрияты, 2001.
4. Гөлбакча. Балалар өчен хрестоматия. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1990.
5. Закирова К.В. Уйный – уйный үсәбез. Казан. Мәгариф нәшрияты 2005.

Прошнуровано.
Пронумеровано: 16 страниц
Зав. МБДОУ № 121 «Сабантуй»
______________________ Ахметзянова Г.Р.